МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.08.2015 г.Казань № 181/2-пр

**Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен раслау турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына гражданнардан мөрәҗәгатьләр керүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен расларга.

2. Эш башкару һәм тикшереп тору бүлегенә Министрлыкка кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен ярты елга бер тапкыр, гомумиләштереп, анализ ясарга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары М.А. Җаббаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

09.01.2015 елның 10/12-11 номерлы ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедураларын билгелиләр.

2. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерүне һәм анализлауны, электрон документлар әйләнеше мәгълүматларына һәм әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә бирелә торган белешмәләргә нигезләнеп, Министрлыкның эш башкару һәм тикшереп тору бүлеге (алга таба – Бүлек) башкара.

3. Бүлеккә министрның, министрның беренче урынбасарының, министр урынбасарларының (алга таба – Министрлык җитәкчелеге, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар) шәхси кабул итүләре вакытында алынган мөрәҗәгатьләр турында мәгълүмат Министрлык җитәкчелегенең шәхси кабул итүенә гражданнарны язып куюны башкара торган белгеч тарафыннан бирелә.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат Бүлеккә хисап чорының соңгы аеннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр җаваплы хезмәткәр тарафыннан бирелә.

5. Анализ ясау барышында Министрлыкка кергән, икенче адресатка җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләр саны турында, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре хакында, шәхси кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнарның исәбе турында, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар хакында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне караганнан соң күрелгән чаралар хакында мәгълүмат, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат өйрәнелә.

6. Бүлек башлыгы 2 пунктта күрсәтелгән, шулай ук әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә кергән мәгълүматны ул кергән көннән алып ике эш көне эчендә гомумиләштерә һәм анализлый, анализны министрның беренче урынбасары белән килештерә.

7. Ясалган анализ нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә төзелә. Аналитик белешмәдә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

кергән, икенче адресатка җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр саны турында;

электрон документ рәвешендә кергән, икенче адресатка җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр саны турында;

хисап чорында Татарстан Республикасы хакимиятенең югары органнарыннан кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре саны турында;

гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;

мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында;

мөрәҗәгатьләрне урынга чыгып карау турында;

узган елгы хисап чорында һәм шул ук чорда тематика буенча гражданнар мөрәҗәгатьләренең саны арту яки кимү турында нәтиҗәләр;

шәхси кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнарның саны турында;

гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм шәхси күчмә кабул итү турында;

мөрәҗәгатьләрне караганнан соң күрелгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта).

8. Мөрәҗәгатьләргә ясалган анализ яртыеллыкның соңгы аеннан соң килә торган айның 15 числосыннан соңга калмыйча Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

9. Кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә ясалган анализ Министрлыкта ачык мәгълүмат булып тора һәм аның белән һәркем Министрлыкның рәсми сайтында (http://.tatarstan.ru) ирекле таныша ала.

10. Вазыйфаи затлар, әлеге Тәртипнең таләпләрен үтәмәгән һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны анализлау срокларын бозган очракта, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән рәвештә җаваплы булалар.